ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законының 43 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 43 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш); 2008, № 1, № 12 (VI өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2014, № 4; 2015, № 7 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3. Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары дәүләт теркәве узарга тиеш. Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт теркәвен узган норматив хокукый актлары, дәүләт серен яки конфиденциаль характердагы мәгълүматларны үз эченә алган актлардан һәм аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, Татарстан Республикасы законнарында, Татарстан Республикасы Президентының һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри рәвештә рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.»;

2) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«6. Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары дәүләт теркәве узган көннән алып 14 көн эчендә республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларына дәүләт теркәве уздыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юллана.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 09 март
№ 8-ТРЗ